**РАСЛЫЙМ**

**Россия ислам институты ректоры**

**Р.М. Мөхәммәтшин**

______________________

**Татар халык авыз иҗаты әсәрләре һәм рухи мирасы үрнәкләрен башкару буенча «Илаһи моң» фестиваль-конкурсы нигезләмәсе**

## I. Гомуми нигезләре

I.1. Татар халык авыз иҗаты әсәрләре һәм рухи мирасы үрнәкләрен башкару буенча «Илаһи моң» төбәкара конкурсын үткәрү турында нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртибен, конкурс эшләренә таләпләр, аларны бәяләү критерийлары һәм принципларын билгели (алга таба – Конкурс).

Татар халык авыз иҗаты әсәрләре һәм рухи мирасы үрнәкләрен башкару буенча «Илаһи моң» төбәкара конкурсын оештыручылар – Бөтендөнья татар конгрессы, Россия ислам институты, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте, Болгар ислам академиясе, ДБУ «Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге», Казан (Идел буе) федераль университеты Халыкара мөнәсәбәтләр институтының ислам һәм ислам дине белемен үстерү буенча ресурс үзәге, «Гөлзада»иҗат студиясе» иҗтимагый оешмасы.

I.2. Конкурсның максаты һәм бурычлары.

Конкурсның максаты: татар халкының мәдәни, рухи традицияләрен үстерү һәм пропагандалау аша җәмгыятьтә милләтара мөнәсәбәтләр һәм татулык мәдәниятен формалаштыруга ярдәм итү.

Конкурсның бурычлары:

- Идел-Урал төбәге халкы арасында мөселман җыр традицияләрен популярлаштыру һәм саклап калу;
- гражданлык-патриотик хисләр һәм туган төбәкнең гореф-гадәтләренә мәхәббәт тәрбияләү;
- яшьләрдә, рухи мирас үрнәгендә, эстетик зәвык, башка диннәргә карата хөрмәт, мәдәниятара диалогка әзерлек формалаштыру;
- тарихи мирасны сәнгати-эстетик яктан кабул итә белүне тәрбияләү;
- яшь һәм өлкән буынның бер-берсен рухи баетуы, рухи һәм мәдәни традицияләрнең дәвамчанлыгын формалаштыру;
- җәмәгатьчелек игътибарын Россия халыкларының рухи традицияләрен саклау проблемаларына җәлеп итү;

- актив яшәү рәвешен пропагандалау;

- Россия ислам институтына укырга керердәй сәләтле һәм талантлы мәктәп укучыларын һәм яшьләрне барлау.

I.3. Конкурс номинацияләре

- Халык авыз иҗаты әсәрләрен башкару (мөнәҗәтләр, бәетләр, эпос-дастаннар, догалар, зикерләр).

- Әдәби мирас үрнәкләрен башкару («Кыйссаи Йосыф», «Бәдавам», «Кисек-баш» һ. б.).

- Татар мәкаме традицияләрендә Коръән уку.

I.4. Конкурста Катнашучылар

Конкурста гомуми белем бирү уку йортлары, башлангыч, урта һөнәри, югары белем бирү учреждениеләре укучылары, шулай ук профессиональ башкаручылар һәм өлкән буын вәкилләре катнаша ала. Катнашучыларның яше чикләнмәгән.

Конкурста аерым башкаручылар да, иҗат төркемнәре да катнаша ала.

Аерым башкаручылар өчен түбәндәге категорияләр каралган:

- «Халык авыз иҗаты әсәрләрен башкару», «Әдәби мирас үрнәкләрен башкару» номинацияләре буенча:

а) 10 яшькә кадәр, б) 10 нан 17 яшькә кадәр, в) 18 дән 54 яшькә кадәр, г) 55+.

- «Татар мәкаме традицияләрендә Коръән уку» номинациясендә:

а) бер категория, яшь ягыннан чикләүләр юк.

Теләгән кешеләргә барлык номинацияләрдә дә катнашырга рөхсәт ителә, бу очракта һәр номинациягә аерым заявка бирелә.

## II. Бәйгене әзерләү һәм үткәрү тәртибе

II.1. Конкурсны әзерләү һәм үткәрүне эшче төркем оештыра. Эшче төркем конкурста катнашучыларны терки, конкурс материалларын җыюны гамәлгә ашыра, конкурста катнашуга кагылышлы сорауларга җаваплар бирә, аңлата, конкурсны үткәрү эшен оештыра һәм башкара.

II.2. Экспертлар төркеме конкурс материалларын тикшерә, бәяли, онлайн форматта, Zoom программасын кулланып, сайлап алу туры үткәрә, йомгаклау этабы өчен эшләрне сайлап ала, конкурс нәтиҗәләре турында хәбәр итә, конкурста җиңүчеләрне бүләкләүне оештыра.

II.3. Эшче һәм экспертлар төркеменә керүчеләр исемлеге конкурсның Оештыру комитеты утырышында раслана.

II.4. Конкурска әзерлек этабы

Эшче төркем тарафыннан «Иләһи моң» татар халык авыз иҗаты әсәрләрен һәм рухи мирасы үрнәкләрен башкару буенча фестиваль-конкурс әзерләү һәм үткәрү нигезләмәсе һәм Юл картасы эшләнелә һәм раслана (2021 нче елның 18 нче гыйнварына кадәр).

Нигезләмә 2021 нче елның 20 нче гыйнварыннан 23 нче гыйнварына кадәр җибәрелә.

Конкурсны гамәлгә куючылар конкурс комиссиясе исемлеген (экспертлар төркемен) раслыйлар һәм оештыру комитетын (эшче төркемне) формалаштыралар.

Оештыру комитеты:

- конкурска эшләр кабул итү турында киң җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирә;
- конкурс материалларын җыя һәм эшкәртә;
- конкурс комиссиясенә бәяләү өчен материаллар әзерли;
- конкурс җиңүчеләрен бүләкләү тантанасын үткәрә.

II.5. Конкурсны уздыру этабы

Конкурс өч этапта үткәрелә:

**I этап** – конкурсантлар фестивальдә катнашу өчен үз чыгышларының видеоязмасы белән заявкаларын җибәрәләр (2021 нче елның 20-25 нче феврале).

**II этап** – сайлап алу туры. Жюри әгъзалары тарафыннан чыгышларның һәм эшләрнең видеоязмаларына бәя бирү (2021 нче елның 26 нчы февраленнән 1 нче мартына кадәр). Шулай ук, Zoom программасын кулланып (якынча 2021 нче елның 6, 7 нче марты), онлайн форматта сайлап алу турын уздыру да каралган.

Онлайн форматта катнашу өчен сылтама заявка биргән катнашучыларга алдан җибәреләчәк. Сайлап алу туры нәтиҗәләре нигезендә оештыру комитеты катнашучыларга конкурсның йомгаклау этабына (2021 нче елның 8, 9 нчы марты) рәсми чакырулар җибәрә.

Сайлап алу турының нәтиҗәләре Россия ислам институты http://kazanriu.ru, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты http://tatar-congress.org, Болгар ислам академиясе https://bolgar kacademy сайтларында урнаштырылачак.

**III этап** – йомгаклау этабы Казанда һәм Болгарда (Болгар ислам академиясе бинасында) узачак (2021 нче елның 27-28 нче марты).

Конкурс кысаларында, квалификация күтәрү курслары, фәнни-гамәли семинарлар, жюри әгъзалары һәм җитәкчеләре катнашында түгәрәк өстәлләр, шулай ук барлык катнашучылар өчен онлайн һәм оффлайн форматта мастер-класслар уздыру каралган.

Квалификация күтәрү курсы программасы кушымта итеп бирелә *(4 нче кушымта)*.

## III. Конкурс эшләренең эчтәлегенә һәм формасына таләпләр

III.1. Барлык номинацияләрдәге конкурс эшләренең эчтәлегенә һәм формасына түбәндәге гомуми таләпләр куела:

- конкурска җанлы башкаруның видеоязмасы кирәк, тавышны һәм видеоматериалны өстәмә эшкәртү рөхсәт ителми;
- чыгышлар традицион формада башкарылырга, яхшы сыйфатлы, ят тавышларсыз булырга тиеш;
- тулысынча яздырылмаган видеоматериал конкурска кабул ителми;
- конкурска җибәрәсе чыгышны башыннан алып ахырына кадәр видеокамераны сүндермичә һәм туктатмыйча төшерергә, монтаж кулланмаска кирәк;
- бер конкурс номерының видеоязмасы 5-7 минуттан да артмаска тиеш;
- видеофайллар AVI, MPG4, MOV (берсен сайлап алырга) форматларында җибәрелә.

III.2. «Халык авыз иҗаты әсәрләрен башкару» (мөнәҗәтләр, бәетләр, эпос-дастаннар, догалар, зикерләр), «Әдәби мирас үрнәкләрен башкару» («Кыйссаи Йосыф», «Бәдавам», «Кисек-баш» һ.б.) номинацияләре өчен конкурс номерының видеоязмасына таләпләр:

- катнашучылардан номерда каралган сәхнә костюмнарында булу сорала;
- иҗат төркеме чыгышында барлык катнашучылар да ачык күренергә тиеш;
- чыгышның файлында иҗат төркеменең исеме яки башкаручының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, шулай ук номерның исеме күрсәтелергә тиеш.

III.3. «Татар мәкаме традицияләрендә Коръән уку» номинациясендә конкурс номерының видеоязмасына таләпләр:

- Коръән укучының чыгышы тәҗвид кагыйдәләренә нигезләнеп әзерләнә;
- укучының киеме дини кануннарга туры килергә тиеш;
- конкурсант чыгышының файлында фамилиясе, исеме, әтисенең исеме күрсәтелә.

III.4. Конкурста катнашу өчен анкета-гариза *(1 нче кушымта)*, конкурс материаллары (видеоязмалар) файллары riitatkafedra@mail.ru электрон адресына кабул ителә. Хат темасында ««Илаһи моң» конкурсына» дип язарга һәм номинациянең исемен күрсәтергә кирәк. Конкурс эшләрен Казан шәһәре, Газовая урамы, 19 нчы йорт, Россия ислам институты, татар теле һәм милли мәдәният кафедрасына (икенче кат, 222 нче бүлмә) да тапшырырга мөмкин. Тел. 8(843) 277-68-26.

## IV. Җиңүчеләрне һәм катнашучыларны бүләкләү тәртибе

IV.1. Җиңүчеләр һәм призерлар өч номинациядә билгеләнә (һәр яшь төркемендә).

IV.1. Конкурс нәтиҗәләре конкурсны оештыручылар сайтында урнаштырыла, шулай ук массакүләм мәгълүмат чараларында да бастырылып чыгарылырга мөмкин.

IV.3. Конкурс комиссиясе нигезләмә буенча конкурста җиңүчеләрне билгели. Шулай ук махсус кызыксындыру бүләкләре дә бирә ала.

IV.4. Конкурста җиңүчеләр «Илаһи моң» фестиваленың йомгаклау гала-концертында катнаша.

*1 нче кушымта*

**татар халык авыз иҗаты әсәрләре һәм рухи мирасы үрнәкләрен башкару конкурсында катнашу өчен**

## АНКЕТА-ЗАЯВКА

(һәр номинация өчен аерым анкета-заявка тутырыла)

**Аерым башкаручылар өчен:**

| Фамилиясе, исеме, этисенең исеме | Яше | Номинация | Авторлары күрсәтелгән репертуар | Эш, уку урыны | Адресы, телефоны, e-mail |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

**Иҗат төркемнәре өчен:**

| Иҗат төркеменең исеме | Җитәкчесенең фамилиясе, исеме, этисенең исеме | Катнашучыларның яше | Номинация | Авторлары күрсәтелгән репертуар | Эш, уку урыны | Адресы, телефоны, e-mail |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | |

*2 нче кушымта*

**Экспертлар төркеме**

1. **Сафиуллина Гөлзада Гомәр кызы**, Татарстанның халык артисты.
2. **Бакиров Марсель Хәернас улы**, филология фәннәре докторы, профессор, ТР Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык авыз иҗаты бүлеге өлкән фәнни хезмәткәре.
3. **Макаров Геннадий Михаил улы**, сәнгать фәннәре кандидаты, Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясенең татар музыкасы һәм этномузыкология кафедрасы доценты.
4. **Садыйкова Айсылу Хөсәен кызы**, филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык авыз иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре.
5. **Җиһаншина Лилия Хаматхарис кызы,** сәнгать фәннәре кандидаты, ДБУ «Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге» халык иҗатын үстерү бүлеге мөдире.
6. **Сайфуллина Гүзәл Рөстәм кызы**, сәнгать фәннәре кандидаты, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, ЮНЕСКО (ICTM) каршындагы традицион музыка буенча халыкара советның төрки телле халыклар музыкасын тикшерү-өйрәнү төркеме әгъзасы.
7. **Сәрвәрова Лилия Илдус кызы,** сәнгать фәннәре кандидаты, доцент, Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясенең татар музыкасы һәм этномузыкология кафедрасы мөдире.
8. **Еникеева Алсу Рәшит кызы**, педагогия фәннәре кандидаты, профессор, Казан дәүләт мәдәният институтының этнохудожество иҗаты һәм музыкаль белем бирү кафедрасы мөдире.
9. **Галимова Эльмира Мөнир кызы**, сәнгать фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге мөдире.
10. **Рәхимов Сөләйман Туктар улы,** Болгар ислам академиясенең ислам мәдәнияте мирасы үзәге җитәкчесе.
11. **Вәлиулин Рөстәм Хәбир улы**, Татарстан республикасы мөфтиенең беренче урынбасары.
12. **Фәезов Рөстәм Рәшит улы**, Казан ислам университеты Коръән-хафизлар әзерләү үзәге директоры.
13. **Хәйруллин Илнур Райнур улы,** Татарстан респубикасы мөселманнары Диния нәзарәте шәригать мәсьәләләре бүлегенең төп белгече.
14. **Габдуллин Зөлфәт Габделманаф улы,** МДО ҺББО КО «Мөхәммәдия» ҮДО – ТР МДН директор урынбасары.

*3 нче кушымта*

**Эшче төркем**

**1. Сафиуллина-Ибраһимова Резедә Риф кызы,** филология фәннәре кандидаты, Россия ислам институтының татар теле һәм милли мәдәният кафедрасы доценты, Казан федераль университетының Халыкара мөнәсәбәтләр институты көнчыгышны өйрәнү, Африка һәм ислам белеме кафедрасы доценты.

**2. Гыйззәтуллина Назирә Әхәт кызы,** Россия ислам институтының уку-укыту бүлеге мөдире.

**3. Тукаев Марс Рифкат улы**, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесенең Россия Федерациясе төбәкләрендәге татар иҗтимагый берләшмәләре белән эшләү буенча урынбасары.

**4. Мифтахова Алсу Равил кызы**, ДБУ «Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге» директоры.

**5. Зигантдинов Ирек Яхи улы**, Болгар ислам академиясенең динара диалог үзәге башлыгы урынбасары.

**6. Гыйззәтуллин Рамил Әнәс улы**, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең фән һәм мәгариф бүлеге мөдире.

**7. Гарипова-Хәсәншина Венера Мәэмүн кызы**, филология фәннәре кандидаты, Россия ислам институтының татар теле һәм милли мәдәният кафедрасы мөдире вазыйфаларын башкаручы.

**8. Кәрибуллин Айдар Әхбар улы,** Россия ислам институты ислам теологиясе кафедрасының өлкән укытучысы.

**9. Фәезов Рөстәм Рәшит улы,** Казан ислам университетының Коръән-хафизлар әзерләү үзәге директоры.

**10.Хайртдинова Ринә Фиргат кызы**, Россия ислам институтының татар теле һәм милли мәдәният кафедрасы УМЭ белгече.

*4 нче кушымта*

Мәгълүмати хат

Татар халык авыз иҗаты әсәрләре һәм рухи мирасы үрнәкләрен башкару буенча «Илаһи моң» фестиваль-конкурсы кысаларында **«Рухи мәдәният әсәрләрен башкару аша тарихи мирасны сәнгати-эстетик яктан кабул итүне тәрбияләү»** курсы игълан ителә.

Белем бирү программасының **бурычлары**:

- Идел-Урал төбәге халкы арасында мөселман җыр традицияләрен популярлаштыру һәм саклап калу;
- гражданлык-патриотик хисләр һәм туган төбәкнең гореф-гадәтләренә мәхәббәт тәрбияләү;
- яшьләрдә, рухи мирас үрнәгендә, эстетик зәвык, башка диннәргә карата хөрмәт, мәдәниятара диалогка әзерлек формалаштыру;
- тарихи мирасны сәнгати-эстетик яктан кабул итә белүне тәрбияләү;
- яшь һәм өлкән буынның бер-берсен рухи баетуы, рухи һәм мәдәни традицияләрнең дәвамчанлыгын формалаштыру;
- җәмәгатьчелек игътибарын Россия халыкларының рухи традицияләрен саклау проблемаларына җәлеп итү.

**Программаның күләме:** 36 сәгать.

**Уку-укыту формасы:** дистанцион белем бирү технологияләрен һәм электрон ресурсларны кулланып уку-укыту.

**Уку вакыты:**15.02.2021 - 22.02.2021.

Уку нәтиҗәләре нигезендә квалификация күтәрү турында таныклык бирелә.

**Курс программасына сылтама:**
https://drive.google.com/file/d/12WmlPfXRjNUyH7gJp3-EdX-8IO-LlSuU/view?usp=sharing

**Катнашу өчен гариза формасы:**
https://forms.gle/PrQDA7ShL2WQMYY56

Элемтә өчен:
Татар теле һәм милли мәдәният кафедрасы
Тел. 8(843) 277-68-26. riitatkafedra@mail.ru

**Өстәмә белем бирү программасы**
**(балаларга һәм өлкәннәргә өстәмә белем бирү)**
**«Рухи мәдәният әсәрләрен башкару аша тарихи мирасны сәнгати-эстетик яктан кабул итүне тәрбияләү»**
**(татар халык авыз иҗаты әсәрләре һәм рухи мирасы үрнәкләрен башкару буенча «Илаһи моң» фестиваль-конкурсында катнашучылар өчен)**
**<u>36 сәгать</u>**

**Модуль 1 «Халык авыз иҗаты. Татарларда әдәби һәм дини мирас»**

**(12 сәгать)**

| Тема | Күләме (ак.сәг.) | Укытучы |
|---|---|---|
| Татар халкының рухи мирасын өйрәнү (дини тәгълимат, илаһият гыйлеме) | 4 сәгать | Сафиуллина-Ибраһимова Резеда Риф кызы, филология фәннәре кандидаты, Россия ислам институтының татар теле һәм милли мәдәният кафедрасы доценты. |
| Әдәбият, сәнгать һәм дин | 4 сәгать | Габдуллин Зөлфәт Габделманаф улы, МДО ҺББО КО «Мөхәммәдия» ҮДО – ТР МДН директор урынбасары. |
| «Сандугач җырын җырлыйм дип, үз җырыңны онытма» (Татар халык авыз иҗаты һәм әдәби мирас) | 4 сәгать | Хабетдинова Миләүшә Мөхәммәтҗан кызы, филология фәннәре кандидаты, КФУның татар әдәбияты кафедрасы доценты. |

**Модуль 2 «Репертуар сайлау һәм рухи мирас әсәрләрен башкару үзенчәлекләре»**
**(16 сәгать)**

| Тема | Күләме (ак.сәг.) | Укытучы |
|---|---|---|
| Мөнәҗәтләр һәм бәетләрнең тематикасы, көйләп китап уку, зикерләр | 4 сәгать | Сафиуллина Гөлзада Гомәр кызы, Татарстан Республикасының халык артисты, Кырым Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе. |
| Дин һәм халык иҗаты | 2 сәгать | Садыйкова Айсылу Хөсәен кызы, филология фәннәре докторы, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының халык авыз иҗаты бүлеге баш фәнни хезмәткәре. |
| Бәет-мөнәҗәтләр көйләп уку сәнгате һәм шигъри текстның метр, ритм сыйфатларын аныклап башкару | 2 сәгать | Макаров Геннадий Михаил улы, сәнгать фәннәре кандидаты, Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясенең татар музыкасы һәм этномузыкология кафедрасы доценты. |
| Мөнәҗәтләр көйләү традициясе | 2 сәгать | Җиһаншина Лилия Хаматхарис кызы, сәнгать фәннәре кандидаты, ДБУ «Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге» халык иҗатын үстерү бүлеге мөдире. |
| Татар этномузыка белемендә фәнни фикерләү формалашу | 2 сәгать | Галимова Эльмира Мөнир кызы, сәнгать фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге мөдире. |
| Идел-Урал татарлары мөнәҗәтләре: локаль традицияләр, чыганаклар. | 2 сәгать | Сәрвәрова Лилия Илдус кызы, сәнгать фәннәре кандидаты, доцент, Н. Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясенең татар музыкасы һәм этномузыкология кафедрасы мөдире. |
| «Аның үз мәкамы бар…» | 2 сәгать | Сайфуллина Гүзәл Рөстәм кызы, сәнгать фәннәре кандидаты, |

| | | |
|---|---|---|
| | | Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе, ЮНЕСКО (ICTM) каршындагы традицион музыка буенча халыкара советның төрки телле халыклар музыкасын тикшерү-өйрәнү төркеме әгъзасы. |

**Модуль 3 «Татар мәкаме традицияләрендә Коръән уку» (8 сәгать)**

| Тема | Күләме (ак.сәг.) | Укытучы |
|---|---|---|
| Коръән-хафизлар әзерләү әһәмияте: Татарстан Республикасы үрнәгендә | 4 сәгать | Фәезов Рөстәм Рәшит улы, Казан ислам университеты Коръән-хафизлар әзерләү үзәге директоры. |
| Татар мәкаме белән Корьән уку традицияләре | 4 сәгать | Хәйруллин Илнур Райнур улы, Татарстан респубикасы мөселманнары диния нәзарәте шәригать мәсьәләләре бүлегенең төп белгече. |